| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

14.12.2021 ел Баулы шәһәре № 49

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Җир салымы турында»гы 2020 елның 23 октябрендәге 12 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы карары нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 октябрендәге 12 номерлы карарына (2020 елның 30 декабрендәге № 20 карары белән кертелгән өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте” сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында»гы 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф.Корбанов